| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЕРХНЕНАЛИМСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ НАЛИМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**31.07.2019** Югары Налим ав. **№ 14**

**«Сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар бүлеп бирү һәм җиһазлау турында»**

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең 2019 нчы елның 10 нчы июлендәге 67/516 номерлы «Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирү һәм җиһазлау турында Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү хакында» карары, Татарстан Республикасы Сайлау Кодексының 64 статьясындагы 8 өлеше нигезендә

**карар бирәм:**

1. Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге сайлау участоклары территориясендә махсус урыннар бүлеп бирергә һәм җиһазландырырга.
2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлегенең сайлау участоклары территориясендә алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен урыннар исемлеген расларга (Кушымта).
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының территориаль сайлау комиссиясенә җибәрергә.
4. Әлеге карарны Зәй муниципаль районы сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә Югары Налим авыл җирлеге мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Ф.Н. Николаева**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Югары Налим авыл җирлеге
Башкарма комитет карарына
Кушымта
31.07.2019 № 14

# Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлегенең сайлау участоклары территориясендә урыннар исемлеге

| № | Сайлау участогы № | Объектның исеме һәм урнашу адресы |
|---|---|---|
| 1. | 1466 | мәгълүмат тактасы - Югары Налим авылы, Яшьләр урамы, 9 йорт |
| 2. | | мәгълүмат тактасы - Югары Налим авылы, Үзәк урам |
| 3. | | авыл клубы – Налим авылы, Гагарин урамы, 45 йорт |